СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

22 август, 1997ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.

№ 93 (8105)

Бәясе билгеләнгәнчә

**Иртәгә - район мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең август киңәшмәсе**

# ҺӘР АЯЗ КӨН КАДЕРЛЕ

## Үзәк штаб контролендә

*20 нче августта 1997 ел уңышын урып - җыю буенча үзәк штабның чираттагы утырышында авыл хуҗалыгы эшләрен төгәл оештыруның стратегик һәм тактик мәсьәләләре каралды.*

*Җитәкчеләрнең төп игътибарын ындыр табакларыннан ашлык чыгаруны оешкан төстә үткәрү, басуларны чистарту, җирләрне туңга сөрү һәм уҗым чәчү буенча эшләрне тизләтүгә юнәлдерүгә аеруча зур игътибар бирергә кирәклегенә басым ясалды. Моның өчен механизаторларның эшен ике сменалы оештырырга кирәк - бу бүгенге көннең катгый таләбе.*

*Ындыр табакларында җаваплы кешеләрнең төнге дежурлыгын оештыру зарури.*

*Утырышта транспорт паркын файдалануга контрольне көчәйтү мәсьәләләре һ.б. күтәрелде.*


## «Уңыш - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

**Район авыл хуҗалыгы идарәсеннән алынган мәгълүматлардан күренгәнчә, 20 нче августка бөртекле һәм бөртекле - кузаклы культураларның 22.110 гектары урдырылды. Бу - барлык мәйданның 45 проценты кадәр. Уңышы җыелган мәйданнар 18.569 гектарга җитте. Барлык мәйданнарның 38 проценты кадәр бу. «Татарстан», «Рассвет», «Дуслык», «Кондырча» хуҗалыкларында урып - җыю темпы аеруча югары.**

**20 нче августка уҗым чәчү 3412 гектарда, ягъни планда каралганның 20 проценты кадәр мәйданда башкарылды. Барлык мәйданнарны аркылыга - буйга чәчү максат ителсә дә, бу ысул белән орлык күмдерелгән мәйдан 2074 гектар гына тәшкил итә. «Киекле», «Төрнәс», «Таң», «Татарстан» хуҗалыкларында чәчү әйбәт оештырылган. Район буенча бу эшне 25 августка тәгәлләү максат ителә. Әлегә туңга сөрү начар оештырылган. Шушы көнгә бу эш планлаштырылган барлык мәйданнарның 8 процентында гына үткәрелде әле.**

**Район хуҗалыклары орлык хәзерләүгә дә оешканлык белән керештеләр. 20 нче августка 3553 тонна салынды ул. Барлыгы 10290 тонна хәзерләү планлаштырыла. Муса Җәлил исемендәге, «40 лет Победы», «Заря», МСО, һәм сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыкларында бу эш сүлпән оештырылган.**

*Яңалыклар*



## Бюро биналы булачак

Хезмәт һәм мәшгульлек бюросы кайда гына «көн күрмәде». Райбашкарма комитеты, хакимият бинасында да «фатир» торды бу оешма. Соңгы тукталышлары - халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү район производство идарәсе бинасында булды. Эшсезләр саны кискен арткан бүгенге көннәрдә кысан биналарда халык кабул итү бюро хезмәткәрләре, шулай ук биредә учетта торучылар өчен дә җитди кыенлыклар тудыра иде. Ниһаять, район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллинның ярдәме нәтиҗәсендә якын киләчәктә бюроның үз бинасы булачак дигән хәбәр ике якны да бик сөендерде. Төзелешнең темпы да моңа ышанычны көннән - көн ныгыта. Июнь уртасында нигез салынган объектның тиз арада беренче каты өелеп куелды. Хәзер подрядчылар - МСО төзүчеләре аның икенче катын күтәрүгә керештеләр.

Район үзәк шифаханәсе поликлиникасы каршында урнашачак бу бинада анда эшләүчеләр өчен дә, бюро хезмәтенә мөрәҗәгать итүчеләргә дә бөтен шартлар тудырылачак.

## Якушкинода мәдәният йорты булачак

Якушкинода яңа мәдәният йорты төзелә башлады. Аның искесе 1954 нче елда төзелгән иде. 4 еллап элек иске, шактый «таушалган» бу бина сүтелде. Шушы чорда авыл яшьләре өчен очрашыр урын да булмады. Ниһаять быел Якушкино авылы җитәкчелеге яңа мәдәният йорты төзүгә керешә. Авыл яшьләре Яңа елны яңа мәдәният йортында каршыларга планлаштыралар.

## Агитпоезд Әлмәттә

Ашлыкны үстерү генә түгел, аны түкми-чәчми җыеп аласы да бар.

Бу көннәрдә «Әлмәт» авыл хуҗалыгы эшчәннәре аның бөртеген дә югалтмыйча суктырып, тизрәк келәтләргә салып кую өчен иген басуларында, ындыр табакларында тиргә батып хезмәт итәләр.

Шундый кызу эшләр кайнаган көннәрнең берсендә, хуҗалыкка районнан «Уңыш-97» агитпоезды килде. Үзешчән артистлар урып-җыю алдынгыларын, хезмәт уңышлары белән котладылар. Игенчеләр Эльмира Җәләлова, Рокыя Исмәгыйлева, Фирдүс Тәмаев, Люция Җиһаншина, Сания апа Котдусоваларның искиткеч матур итеп җырлауларын, Әлфирә Җәләлова һәм Надежда Рязановаларның очып-очып испан, татар, чегән биюләрен бшкаруларын сокланып карадылар. Шул вакытта Маргарита Логинова бушлай чәч кисү белән шөгыльләнде.

Әлмәтлеләр агитпоезд чыгышын бик ошаттылар. Басуда тагын да тырышып эшләүгә көчләре артканын тойдылар алар.

**З.ТАҺИЯТУЛЛИНА,**
**китапханәче.**

# Хәерле сәгатьтә булсын!

Узган уку елы үзенең хезмәт киеренкелеге һәм нәтиҗәлелеге белән аеруча истә калды. Бердән, узган елның ноябрендә Татарстан Республикасының Мәгариф министрлыгыннан килгән махсус комиссия соңгы 7 елдагы эшчәнлегебезне тикшереп, район мәгариф бүлегенең хезмәтен уңай бәяләп китте. Уку елы башында ук булган бу тикшерү алдагы эшчәнлегебезгә куәт өстәде һәм кыйблабызны ныгытты дияргә була.

Район мәгариф бүлеге үзенең эшен максатчан һәм системалы алып бара. Төп максат дигәннән, беренче чиратта Татарстан Республикасының «Мәгариф турында» һәм «Телләр турында»гы Законнарын алга куеп эшлибез. Районыбыз күпмилләтле булганлыктан, дәүләт теле буларак татар һәм рус телләрен өйрәтүдән тыш, мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында милли төркемнәр эшли һәм татар, чуваш телләре туган тел буларак өйрәнелә.

1996 - 97 уку елында районда 40 урта, 3 тулы булмаган урта, 21 башлангыч мәктәптә 10165 укучы белем алды һәм 40 балалар бакчасында 2514 бала тәрбияләнде. Шул исәптән 5 гимназия, 1 укыту - тәрбия комплексы, 1 лицей һәм төрле фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 23 мәктәп уңышлы эшләде.

Ә инде аларның эшен оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру: югары белемле укытучылар хәзерләү, мәктәптә чит телләр өйрәнүне кертү һәм камилләштерү буенча программалар булдыру, мәктәптән тыш тәрбия, ял вакытын оештыру, укыту - тәрбия эшенең сыйфатын яхшырту, яңа тип уку йортлары ачу һәм башка шундый мәсьәләләрне хәл итү эшчәнлегебезнең төп эчтәлеге булды.

Мәктәп укучыларының саны шәһәр мәктәпләрендә елдан - ел арта бара. Шуңа бәйле рәвештә дәресләрне классларның алмашып уку тәртибендә (ягъни сменалап) оештырырга туры килә. Моның шулай ук үз кыенлыклары, үз мәшәкатьләре җитәрлек.

Узган уку елында шәһәр мәктәпләрендәге тыгызлыкны бераз киметү максатыннан Норлатта башлангыч мәктәп - бакча дип аталган 3 укыту - тәрбия комплексы ачылды. (Болар «Камыр Батыр», «Кояшкай», «Әкият» балалар бакчалары базасында оештырылды).

Район мәгариф бүлеге җирле үзидарә органнары һәм база хуҗалыклары белән берлектә уку йортлары бина元ары төзү буенча да эш алып барды. Узган уку елында Якты Күл, Заречный, Бутаиха авылларында яңа мәктәп биналары укучылар кабул итте.

Татарстан Республикасының «Мәгариф турында»гы Законын гамәлгә ашыру максаты белән район мәгариф бүлеге балаларның сәләтен, мавыгуларын үстерү өчен мөмкинлекләр тудыру хакында да кайгырта. Хәзерге вакытта яңа тип уку йортлары ачу нәкъ менә шул максаттан чыгып эшләнде.

(Ахыры 2 нче биттә).

## Укытучы мәктәп һәм үзе турында

*Татьяна Николаевна Маслова:*

## «Мәгарифебезнең яхшы киләчәгенә ышанам»

***Норлатның 2 нче рус - татар мәктәп гимназиясенең химия укытучысы, Татарстанның атказанган укытучысы Татьяна Николаевна Маслова ВУЗ студентларын сораштырганда Россиянең 73 регионының иң яхшы укытучылары рәтендә телгә алынган. Хезмәттәше Надежда Васильевна Коннова белән бергәләп ул төгәл фәннәр өлкәсендә белем бирү программасы турында җиңеп, Сорос грантына ия булды.***



**(Аның белән әңгәмәне 2 - 3 нче битләрдән укыгыз)**

## Ярминкә - укучыларныкы

Укытучыларның август киңәшмәсе көнендә укучылар ярминкәсе оештыру матур традициягә әверелде. Бу күркәм гадәт быел да сакланачак. 23 нче август көнне шәһәрнең үзәк мәйданында үтәчәк ярминкә. Арзан бәядән яшелчә, җиләк - җимеш сатып алырга теләгегез булса - мәйданга рәхим итегез. Шәһәрлеләргә шулай ук укучылар куллары белән тегелгән кием - салым, дәресләрдә эшләнгән уенчыклар, эш кораллары, урман хәзинәләре дә тәкъдим ителәчәк.

Ярминкә иртәнге сәгать 6да ачылачак.

**( Август киңәшмәсенә багышланган язмаларны газетабызның 2 - 3 - 4 битләреннән укый аласыз).**

# ТӨПЛЕ БЕЛЕМ, КАМИЛ ТӘРБИЯ БИРҮ -

# Хәерле сәгатьтә булсын!

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә).**

Гимназия класслары ачылуга ата - аналар да, укытучылар да зур өметләр багъладылар. Бу классларда гомуми сәгатьләр саны элекке күләмдә калса да, гадәти мәктәптәгедән үзгәрәк яңа фәннәр (мәсәлән, риторика, фольклор, башлангычта ук чит тел өйрәнү) кертелде. Бу яңалыкларны балаларның зур теләк белән, җиңел үзләштерүе күзәтелә. Әлеге фәннәрне яшьтән өйрәнү баланың сәләтен күбрәк ачарга мөмкинлек бирә, куелган хезмәтебез үзен күбрәк аклый.

Район укытучылар коллективының профессиональ хәзерлеген арттыру, яшь белгечләр хәзерләү эшен дә гел күз уңында тотабыз. Елның - елында югары уку йорты тәмамлаган яшьләребез районыбыз укытучылар сафларын тулыландыра. Белгечләргә аеруча зур кытлык булган фәннәр (мәсәлән, музыка, рәсем, сызым, хезмәткә өйрәтү, чит телләр) буенча белгечләр хәзерләү өчен шартларны ел дәвамында өйрәнеп, аеруча сәләтле яшьләрне махсус уку йортларына алып барып таныштырабыз. Шунлыктан, укучыларыбыз керү имтиханнарына инде максатлары белән мөмкинлекләрен чамалап, билгеле дәрәҗәдә мәгълүматлы булып, теоретик хәзерлек белән баралар. Быел 7 укучыбыз - рәсем - сызым, 7 укучыбыз музыка буенча белгечлек алу максаты белән Лениногорск шәһәрендәге 1 нче педагогия училищесына укырга керү бәхетенә иреште.

Узган уку елы соңгы еллар белән чагыштырганда аеруча мул уңыш бирде. Язын мәктәп тәмамлаган 524 укучының 15е - алтын, 44е көмеш медальгә лаек булды.

Чыгарылыш класс укучыларыбызның югары һәм махсус урта уку йортларына керү дәрәҗәсе дә узган елгы белән чагыштырганда күпкә югарырак. Бу уку елында 6 нчы һәм 8 нче класслардан 3 укучыбызның Түбән Каманың Г.Тукай исемендәге татар - төрек лицеена укырга керүе шулай ук укытучыларыбызның дәвамлы хезмәт нәтиҗәсе дип бәяләнә.

Узган уку елында мәктәпләребезнең материаль - техник дәрәҗәсен яхшырту ягыннан да шактый эш башкарылды. Һәр мәктәптә җиләк - җимеш бакчалары булдырылды; мәктәп яны тәҗрибә участоклары һәм мәйданчыклар тәртипкә китерелде. Районыбызның 7 мәктәбе һәм балалар бакчасы газ белән җылытуга күчерелде, тагын 20 мәктәп һәм балалар учреждениесен газ белән җылыту өчен кирәкле җиһазлар тулысынча хәзерләнде.

Мәктәпләр язгы чыгарылыш мәшәкатьләре бетәр - бетмәс үк җәйге ремонт эшләренә керешкәннәр иде. Август башында бу эшләр тәгәлләнде. Һәр мәктәп хуҗалары үзенең укучыларын кабул итүгә бик тырышып хәзерләнде. Быелгы уку елына хәзерлек вакытында аеруча күләмле эшләр башкарган мәктәп коллективларыннан Илюткино, Гәйтән, шәһәрнең 4 нче гимназиясе, Егоркино, Каравыл Тавы, Сәләнгеш һәм «Чишмәкәй» гимназиягә хәзерлек учреждениесен, Югары Норлат, Тимерлек, «Светлячок», Урта Камышлы балалар бакчаларын атап әйтергә мөмкин.

Быел җәй безнең мәктәпләребез исемлегенә бер яңа мәктәп өстәлде: ул - Норлат шәһәренең 8 нче урта мәктәбе дип атала. Бу мәктәп моңарчы тимер юлчылар бистәсендә эшләп килгән 61 нче урта мәктәп базасында оештырылды. Моңача Рәсәй бюджетыннан үги хәлендә генә финансланган бу уку йортын һәр яктан шәһәребезнең башка мәктәпләре дәрәҗәсенә җиткерү өчен ай - һай күп тир түгәргә туры киләчәк әле.

Гомумән алганда, район мәгариф бүлегенең узган елгы эшчәнлеге нәтиҗәле булды. Шуңа күрә яңа уку елына да яңа планнар, иҗади рухлану белән киләбез.

Районыбызның 1603 укытучыдан торган олы коллективын якынлашып килүче Яңа уку елы белән котлап, «Хәерле сәгатьтә булсын, хезмәттәшләр!» диясем килә.

**Н.АБДУЛЛИН,**
**район мәгариф бүлеге мөдире.**

## *Хезмәте белән хөрмәтле*



Таныш булыгыз: рәсемдә 1 нче «Чишмәкәй» мәктәпкәчә гимназия директорының укыту - методик эш буенча урынбасары Татьяна Кожевникова. Хезмәт стажы ике дистә елдан артык аның. Мәгариф отличнигы, югары квалификация категориягә ия җитәкче. Үз вазифасын яхшы белүче, эзләнеп эшләүче, хезмәтен яратып башкаручы, инициативалы кеше. Аны башкалардан эшкә иҗади мөнәсәбәт, киң эрудиция, югары таләпчәнлек, тыйнаклык аерып тора. Татьяна Николаевна үзенең шәхси өлеше белән коллективта эзләнү атмосферасы тудыра белә, үзенең белем һәм тәҗрибәсен тәрбиячеләргә методик ярдәм күрсәтүдә файдалана. Ә хезмәт нәтиҗәләре һәрчак бер дигән: анарда тәрбияләнә торган балаларның интеллект үсеше темпы аларның актив мөмкинлекләренә, белем дәрәҗәсе исә дәүләт стандартына тәңгәл килә. «Чишмәкәй»нең районда ата - аналар арасында югары рейтинг тотуы да шул хакта сөйли.

Татьяна Николаевна балалар бакчасы тәрбиячеләренең алдынгы тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату буенча да зур методик эш алып бара, алар белән эшләүдә яңа, актив формалар эзли, аларның һәрберсенең иҗатын, һөнәри осталыгын ачып бирерлек булуына ирешүне беренче планга куя. Эшлекле уеннар, КВН формасындагы дискуссияләр, педагогик ринглар - болар барысы да тәрбиячеләрне ачыктан - ачык фикер алышуга, конкрет ситуацияне анализлауга, хәлиткеч чаралар күрүгә этәрә, дискуссия культурасына өйрәтә. Шул ук вакытта коллективның бердәмлеге артуга да булыша, хезмәттәшләре арасында аралашу дәрәҗәсен күтәрә.

Татьяна Николаевна ата - аналар белән дә зур эш алып бара. Алар белән ял кичәләре, түгәрәк өстәл артында сөйләшүләр һ.б. үткәрә. Шуның өчен дә һәммәсе хөрмәт итә аны.

## *Рәхмәт Сезгә!*

Укытучы ул белем бирүче генә түгел, ә тәрбияче дә, укучы күңеленә юл табучы да. Мин шундыйларның берсе - Югары Норлат урта мәктәбе укытучысы Нәфисә Таһировна Төхвәтуллина дияр идем. Нәфисә апа белем бирү өлкәсендә 3 дистә еллар эшли инде. Ул үзенең дәресләрен һәр укучыга якын килеп үткәрү, аларга ныклы белем, яхшы тәрбия бирү өчен бөтен тырышлыгын куя. Нәфисә Таһировна районда татар теле укытучыларыннан беренче булып әйдәп баручы укытучы исеменә лаек булды. Мәктәптә Нәфисә апа үзенә генә хас таләпчәнлеге, сабырлыгы, олы җанлы укытучы булуы белән аерылып тора. Мондый сыйфатлар аңа гомер буе укытучы булып эшләгән әтисе Таһир ага Гатиновичтан күчкәндер мөгаен. Нәфисә апа һәр укучының белеме өстендә эшләү өчен өстәмә сәгатьләр оештыра, вакыт белән һичкайчан санашмый. Шуңа күрә дә, югары уку йортларына керүче укучылар арасында аның фәннәре (татар теле һәм әдәбияты) буенча китүчеләр күп. Олы җанлы укытучы студентлар белән дә тыгыз бәйләнештә тора, үз укучыларының шатлыкларына шатланып, кайгыларына кайгырып яши һәм эшли.

Нәфисә Таһировна мәктәптә яраткан укытучы булса, өендә ул өч балага ягымлы ана, ире Ислам абыйга яхшы тормыш иптәше. Матур, мул, тәртипле тормышта яши Төхвәтуллиннар гаиләсе. Олы уллары Илшат төзүчеләр институтын тәмамлап мастер булып эшли. Икенче балалары Миләүшә әнисе эзеннән китте - быел гына КДУның татар филологиясе һәм көнчыгыш телләр факультетын тәмамлап, кулына диплом алды. Ул да укытучы булырга җыена. Ә төпчекләре Илнар әле мәктәптә генә укый. Тик шулай да йорт эшләрен үз өстенә алып әнисенә ярдәм итәргә тырыша. Кыскасы, күпләргә үрнәк булырлык ул Төхвәтуллиннар гаиләсе. Рәхмәт сиңа, укытучым, безгә белем биргән, кайгыртып яшәгән өчен.

**З.ӘХСӘНОВА.**

### *Татьяна Николаевна Маслова:*

# «Мәгарифебезнең яхшы киләчәгенә ышанам»

**Бала чагында ул табиб - хирург булырга хыялланган, әмма менә инде 24 нче ел 1 нче сентябрьдә мәктәп бусагасын атлап керә. Аның «Ирешелгәннәрдә тукталып калмаска, камиллеккә омтылырга» дигән тормыш девизы бер үк вакытта гади дә, буй җитмәслек тә, чөнки ул шәхеснең даими эзләнүен күздә тота.**

**Кешеләрдә акыл, һөнәрмәнлек, тәртиплелек кебек сыйфатларны югары бәяли, ә инде үзенең характерына хас сыйфатлар арасында хезмәт сөючәнлек, намуслылык, изге күңеллелек кебекләре аермачык булып беленеп тора. Аңардагы ягымлылык, әчке сабырлык, рухи олылык кебек сыйфатлар шулкадәр күзгә бәрелеп тора ки, аның белән бер очрашып сөйләшүдән дә үзеңдә ул кешегә карата мәхәббәт уянуын сизми дә каласың.**

**Үзара килешеп, без әңгәмәбезне ике өлешкә бүлдек. Алар икесе дә бер - берсе белән тыгыз бәйләнгәннәр һәм бер берсен тулыландыралар.**

## Мәктәп һәм укучылары турындагысы

**- Татьяна Николаевна, укытучыдан иң элек нәрсә турында сорыйсың инде... Мәктәп хакында, шулай бит? Укучылар һәм аларның ата - аналары белән мөнәсәбәтләрдә Сез нинди принципларны алга куясыз?**

- Укытучы булып эшли башлау белән мин укучылар өчен укытучының иң беренче чиратта кешелек сыйфатлары мөһим булуын, алар өчен укытучы - иң элек шәхес икәнлеген һәм безнең аларга карата мөнәсәбәтебез әһәмиятле роль уйнавын аңладым. Ә инде сез сораган принциплар укытучының кешелек сыйфатларыннан килеп чыга. Принципларым мондый: балаларга, бигрәк тә өлкән класстагыларына эшлекле, таләпчән, игелекле, хөрмәт белән карау. Балаларның әти - әниләре белән мөнәсәбәтләрдә дә шул ук принципларны тотарга тырышам.

**- Сез үз укучыларыгызның язмышлары белән кызыксынып торасызмы? Алар сезгә шалтыраталармы, хат язалармы? Һәм инде Сез үзегезнең укытучыларыгызны хәтерлисезме?**

- Укучыларымның мине онытмаулары, минем мәктәптәге эшләрем белән кызыксынып, сәламәтлегемне сорашып торуларыннан бик канәгать мин. Үзем дә аларның язмышларына битараф түгелмен. Укытып чыгарган укучыларым арасында табиблар, инженерлар, укытучылар... бар. Укучыларым үз язмышларын мин нигезләрен укыта торган химия фәне белән бәйләсәләр бик горурланам. Андыйлар коллегаларым арасында да бар инде - химик - биолог Любовь Александровна Сапова. Үз укытучыларымнымы? Хәтерлим, билгеле. Мәктәптә дә, институтта да күп булды алар һәм мин барысын да

# Методик берләшмә - зур көч

*«Надан дәрәҗәгә омтыла, галим - камиллеккә».*
*(халык мәкале).*

«Балаларны ничек укытырга?» һәм «нәрсәгә өйрәтергә?» дигән һ.б. сораулар кискен торган хәзерге чор бездән методик берләшмә эшен дә камилләштерүне таләп итә.

Узган уку елы алдыннан без татар теле һәм әдәбияты укытучыларына «Сезгә нәтиҗәле эшләргә нәрсә комачаулый?», «Методик берләшмә эшен оештыру өчен сез нинди тәкъдимнәр әйтер идегез?», «Программалар һәм укыту методикасы турында нинди фикерләрегез бар?» дигән сораулар язылган анкета тәкъдим иткән идек. Берләшмәнең август утырышында шушы мәсьәләләр хакында да эшлекле сөйләшү булды һәм без берләшмәнең еллык планын кабул иттек.

Мәктәп алдына куелган бурычларны бары тик югары абруйлы, тирән белемле, педагогик сәләткә һәм осталыкка ия булган укытучылар гына гамәлгә ашыра ала. Шуңа күрә без берләшмә утырышларында педагогика, психология һәм методика буенча фәнни - теоретик семинарлар, докладлар, лекцияләр үткәрүне планлаштырдык. Уку елы барышында һәрбер укытучы үзе сайлап алган яки тәкъдим ителгән тема буенча эчтәлекле докладлар белән чыгыш ясады.

Ачык дәресләр, класстан тыш тәрбия чаралары үткәрү дә планда каралганча зур төгәллек белән уздырылып килде. Аларның һәрберсе мәктәпнең һәм укытучының өйрәнелә торган темасына туры китерелеп башкарылды. Стандарт булмаган дәресләр үткәрү, укытучыларның иҗат лабораториясе белән танышу, алдынгы педагогик тәҗрибәне өйрәнү педагогларыбыз үз - үзләренә бик таләпчән, иҗади эшлиләр, экспериментлар үткәрәләр, алдынгы педагогик тәҗрибәне үз эшләрендә иҗади кулланалар, укыту - тәрбияне камилләштерәләр дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирде.

Үзара тәҗрибә уртаклашу коллективта эшлекле мөнәсәбәтләр тудыра, иҗади эзләнү теләге уята. Укытучылар дәресләрне анализларга өйрәнәләр, аларны чагыштырып карау мөмкинлеге алалар. Бигрәк тә Р.Гыйлемшина, Р.Яруллина, Н.Мөлекова, Г.Айзатуллина, Р.Вәлиуллина, Н.Һадыева, Н.Хәмитова, Р.Алякимова, И.Сираҗева тарафыннан бирелгән ачык дәресләр укытучыларда уңай тәэсир калдырды, үрнәк дәресләр дип кабул ителде. Март аенда үткәрелгән татар теле һәм әдәбияты декадасы - шулай ук берләшмә әгъзаларының хезмәт җимеше. Бу чарада укучылар белән беррәттән ата - аналар да актив катнаштылар. Төрле әдәби кичәләр, бәйрәмнәр, конкурслар, ярышлар үткәрү балаларга өстәмә белем бирәләр, аларда туган телне, әдәбиятыбызны, сәнгатебезне ярату, милләтебез белән горурлану хисләре тәрбиялиләр.

Уку елы барышында Г.Ибраһимовка, Мөхәммәдъярга, С.Сәйдәшевкә, Г.Исхакыйга, Г.Тукайга һ.б. язучыларга, сәнгать әһелләренә багышлап үткәрелгән дәресләр һәм тәрбияви чаралар укучыларда һәм ата - аналарда аеруча җылы тәэсир калдырды.

Узган уку елында методик берләшмә утырышында тагын бер бик җитди мәсьәләгә - әдәбият дәресләрендә туган якны өйрәнү материалларыннан файдалануга игътибар юнәлдерелде татар теле һәм әдәбияты кабинетына «Күренекле якташларыбыз - районыбыз картасында» дигән стенд ясап элдек. Аларның тормыш юлы, иҗаты, хезмәтләре турында материал туплый башладык, шуларны әдәбият дәресләрендә, класстан тыш чараларда актив кулланабыз. Аларны җыюда ата - аналар, укучылар да актив катнаша. Бу эш - туган якны, телне, гореф гадәтләрне җентекләп, бөртекләп өйрәнергә өйрәтә, укучыларда туган туфракка ихтирам, горурлану хисе тәрбияли.

Шунысын да әйтергә кирәк, уку елы дәвамында методик берләшмә үзенең киңәшмәләрен төрләндеребрәк, үзенчәлеклерәк итеп тә үткәрергә тырышты. Мәсәлән, «Җомга көн кич белән» «Театр һәм без», «Чәй янында сөйләшү» шикелле үткәрелгән утырышлар да булды.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: укытучылар коллективының эшчәнлеген уртак максатка юнәлткәндә, коллективта эшлекле мохит, бердәмлек булганда, методик берләшмәнең эшен программалы, максатчан итеп оештырганда балаларга белем һәм тәрбия бирүдә яхшы нәтиҗәләргә ирешеп була.

**Р.ФӘЙЗУЛЛИНА,**
**2 нче мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучыларының методик берләшмәсе җитәкчесе.**

---



Мәктәптән тыш учреждениедә эшләүче педагог нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Иң элек оештыру осталыгынадыр, мөгаен. Балаларның игътибарын җәлеп итәрлек күп белүе, сөйләү осталыгына ия булуы да мөһим. Гомумән, балаларның мәктәптән тыш вакытын кызыклы, шул ук вакытта файдалы да итеп оештыру таләп ителә аңардан. Ә менә балалар - яшүсмерләр үзәгенең оештыру - масса бүлеге мөдире М.Н.Гиняева бу сыйфатларның барысына да ия дисәк тә арттыру булмас. Ул тыгыз элемтәдә эшләгән мәктәпләрнең ,тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары, укытучылар, вожатыйлар да раслыйлар моны. Минзәлия Нурәхмәтовна балалар белән нинди генә чаралар үткәрми. Өлкән класстагылар өчен даими уздырыла торган «Интеллект - шоу», «Калейдоскоп», «Фольклото», «Джентельмен - шоу» һ.б. чаралар, «Туган як серләре» экспедициясе, Татарстан варислары белән алып бара торган мәгълүматка бай кызыклы кичәләрне балалар һәрчак көтеп алалар. Шуңадыр, бу чаралар һәрчак массовый төс ала.

Гомумән, үзәктә оештыру эше таләп иткән бер генә чара да Минзәлия Нурәхмәтовнаның якыннан катнашыннан башка узмый.

Болардан тыш, менә инде ике ел рәттән Гиняева район мәгариф бүлеге каршында оештырылган «Яшүсмер» профиль лагеренда педагог - оештыручы булып та эшли.

- Иң оста тәрбиячеләребезнең берсе ул,- ди аның турында район мәгариф бүлегенең мәктәпләрдә тәрбия эше өчен җаваплы методисты Г.Д.Әһлиуллина.

**Рәсемдә: М.Н.ГИНЯЕВА.**

---

# *Котлыйбыз!*

Киекле авылында яшәүче кадерлебез **Фәридә Галәветдинованы** туган көне белән котлыйбыз. Нык исәнлек, тормыш иптәше белән бергә татулыкта, тигез гомер итүен телибез. Киң күңеллелегең, кешелеклелегең өчен без сине яратабыз, гомергә бергә бәхетле гомер кичерергә насыйп булсын иде дип телибез.

**Улың Илнар, киленең Люция, оныгың Ләйлә, кода - кодагыең.**

Норлат шәһәрендә яшәүче әнибез **Халисә Гаяз кызы Хәлиуллинаны** 60 яшьлек юбилее белән котлыйбыз.

60

Ак бәхетләр юлдаш булсын сиңа,
Тормышыңны шатлык бизәсен.
Сәламәтлек - ярты бәхет диләр,
Бигрәк шунысы читләтеп үтмәсен.

**Рәис, Рәзилә, Эльмира, Динара.**

## Белдерүләр

### *Сатабыз*

**60 лет Октября урамында 2 бүлмәле фатир.** Адрес: тел.: 5 - 18 - 14.

***

**Ике бүлмәле фатир.** Адрес: Советская ур., 195 - 36.

***

**Бер бүлмәле фатир**. Адрес: Карл Маркс ур., 27 - 1. Тел.: 2 - 18 - 46.

***

**Ашыгыч төстә 1990 елда чыккан, 1997 елның маенда двигателенә капиталь ремонт ясалган, йокл[а] урыны, 20 т. контейнеры, бүлгече, 500 л.багы булга[н] «КамАЗ» - 53212. Бәясе килешү буенча.**
Тел.: 2 - 21 - 02.

***

**1996 елда чыккан ВАЗ - 21061**. Тел.: 5 - 24 - 12 (14.00 сәг.тән соң мөрәҗәгать итәргә).

***

**Ашыгыч төстә арзан бәягә 3 бүлмәле фатир.** Адрес: Московская ур., 5 - 45 (17 сәг.тән соң).

***

**1997 елның гыйнвар аенда чыккан ВАЗ - 21083, 35 млн. сумга.** Тел.: 5 - 21 - 94.

***

**2 - 3 көн эчендә язып биреп кабер ташлары. Бәясе - килешү буенча.**
Адрес: Ленинград ур., 14. Таныклык № 324.

***

**1985 елгы, әйбәт хәлдәге ВАЗ - 2106**.
Тел.: 2 - 29 - 19 (теләсә кайчан).

***

**КАВЗ автобусы, үзбушаткыч ЗИЛ машинасы**. Адрес: Кошка районы, «Автомобилист» совхозы, Долиновка авылы, тел.: 2 - 20 - 55.

### *Алмаштырабыз*

**Димитровград шәһәрендәге аз гаиләләләр өчен йорттагы 12 кв.м.лы бүлмәне - Норлатта шундыйга ук**. Тел.: 2 - 24 - 58.

***

**2 бүлмәле фатирны - Кормыш микрорайонында 1 бүлмәлегә (1 һәм 5 нче каттан һәм аз гаиләләләр өчен йорттан тәкъдим итмәскә)**. Адрес: Советская ур., 183 - 12.

### *Табучы юкмы?*

**Рамил Әсхәт улы Насыйбуллин исеменә документлары белән сумка табучының бүләк бәрабәренә Мәскәү ур., 5 - 19 адресы буенча кайтарып бирүен сорыйбыз.**

### *Эшкә чакырабыз*

**«Колос» ресторанына официантлар кирәк.**

### *Идел Буе региональ наркология үзәге*

***Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.***
***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, 29 августта, 12 сентябрьдә көндезге сәгать 2 дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2334 данә. **Заказ № 8432**